**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1173**
**19.02.2021**

«Татар малае» (1-4 сыйныф укучылары) муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте программасын тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, балаларны туган телгә, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү, эстетик тәрбияләү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә «Татар малае» (1-4 сыйныф укучылары) муниципаль конкурсын (алга таба - конкурс) оештыру һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 50 000 (илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 19 февралендәге
1173 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татар малае» (1-4 сыйныф укучылары)
муниципаль конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Татар малае» (1-4 сыйныф укучылары) муниципаль конкурсы (алга таба - конкурс) яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, балаларны туган телгә, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү, эстетик тәрбияләү, конкурста катнашучыларның башкару осталыгын күтәрү максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү;

2) укучыларның игътибарын татар халкының рухи традицияләренә җәлеп итү;

3) укучыларның татар телендә иркен аралашу дәрәҗәсен күтәрү;

4) укучылар һәм ата-аналарның игътибарын балалар әдәбиятына һәм укуга җәлеп итү;

5) белем бирү оешмаларында мәктәп яшендәге балаларның иҗади потенциалын үстерүгә шартлар булдыру;

6) балаларда лидерлык сыйфатлары формалаштыру;

7) яшь талантларның профессиональ сәхнәгә чыгуларына ярдәм күрсәтү;

8) укучыларны шәһәр һәм республика конкурсларында, чараларында катнашуга әзерләү.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурста шәһәр белем бирү оешмаларының татар телен белә торган 1-4 сыйныф укучылары катнаша ала.

4. Конкурста катнашу ирекле.

5. Конкурста катнашу өчен кандидатларны тәкъдим итү белем бирү оешмалары коллективлары яки ата-аналар тарафыннан башкарылырга мөмкин.

6. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән расланган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

7. Оештыру комитеты һәр этапта конкурс үткәрүгә йомгак ясый, шулай ук конкурсның җиңүчеләрен билгели.

8. Конкурс өч этапта үткәрелә.

9. I этап 2021 елның 26 февраленнән 2021 елның 4 мартына кадәр белем бирү оешмаларында үткәрелә:

Конкурсның 1 этап программасы ике өлештән тора:

1) «Визит карточкасы» - катнашучы индивидуаль формада яки төркем катнашында «Татар булып тудым – бәхетле мин, татарлыгым минем – иманым» темасына иҗади визит карточкасын күрсәтә (чыгыш 5 минутка кадәр);

2) сәнгать номеры, 4 минутка кадәр.

Конкурсның I этабы нәтиҗәләре буенча II этапта катнашу өчен һәр белем бирү оешмасыннан бер катнашучы чыгарыла. Конкурсның II этабында катнашу өчен конкурста

катнашучылар 2021 елның 11 апрельгә кадәр срокта odmoo.saifullina@yandex.ru адресына түбәндәге формада заявка бирәләр.

Заявка формасы

| бб/о | Катнашучының Ф.И.А.и., сыйныфы | Җаваплы җитәкче, телефон |
|---|---|---|
| | | |

10. II этапта катнашучылар портфолио һәм визит карточкасы әзерлиләр. Портфолио 2021 елның 11-12 мартларында «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе адресы буенча (Чулман-88 (44/16), 309 кабинет) кабул ителә.

11. Портфолиога таләпләр:

1) «Минем портрет» бүлеге;

- конкурсантның шәхси мәгълүматлары;
- автобиография;
- хобби;

2) «Минем гаиләм» бүлеге:

- гаилә кыйммәтләре;
- берлектә тормышка ашырылган проектлар.

3) «Шәхси документлар» бүлеге:

-портфолиога кертелгән рәсми документлар исемлеге;

- конкурсантларның төрле төрдәге эшчәнлеккә өйрәнүдәге шәхси уңышларын дәлилли торган барлык сертификацияләнгән документлары; төрле дәрәҗәдәге предмет олимпиадаларында, конкурсларда, конференцияләрдә катнашып алган грамоталары, дипломнары һәм башкалар (төп нөсхәләр);

4) «Минем эшләрем» бүлеге:

- конкурсантларның татар халкының милли традицияләрен, гореф-гадәтләрен өйрәнүгә һәм саклауга, татар теленең статусын күтәрүгә юнәлдерелгән проектлары, тикшеренү, иҗат эшләре: рефератлар, иншалар, рәсемнәр, проект эшләре, мәктәптә яки мәктәптән тыш чыга торган газета мәкаләләре;
- конкурсантның өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, төрле укыту курсларында шөгыльләнүе турында мәгълүматлар;
- конкурсантның портфолио алып бару срогы дәвамында барлык төр иҗат эшчәнлеге языльп барыла торган «Минем мәктәп һәм мәктәптән тыш чараларда катнашуым» дигән таблицасы;
- конкурсантның җәмәгать эшчәнлеге турында мәгълүматлар;

5) «Миңа бәяләмә» бүлеге:

- ата-аналар;
- сыйныфташлар;
- укытучылар.

12. Портфолионы бәяләү критерийлары:

1) пөхтәлеге һәм эстетик бизәлеше;
2) ачыклыгы;
3) структуралылыгы;
4) эчтәлек дәрәҗәсе;
5) бизәлешнең бердәм стиле.

13. Визит карточкаларын бәяләү критерийлары:

1) татар телен белү;
2) сәхнәдә үзен тоту осталыгы;
3) актерлык осталыгы һәм сәхнә сөйләме дәрәҗәсе;
4) индивидуальлек;
5) музыканың, җырның, шигырьнең эчтәлеге балаларның яшенә туры килү;

6) концерт номерларының камиллеге;

7) костюмнарның эстетик ягы.

14) II этап нәтиҗәләре буенча 10 катнашучы конкурсның финалында катнашу өчен чыгарыла.

Финалда катнашучылар вокал, хореография буенча куючы белән репетицияләрдән торган махсус әзерлек үтәләр һәм интеллектуаль викторина буенча консультация алалар.

15) Финал конкурсның 3 биремен үз эченә ала.

1) визит карточкасы;

2) интеллектуаль викторина;

3) импровизация.

16. Конкурсның финалы 2021 елның апрель-маенда «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесенең театр залында шоу-программа рәвешендә үтәчәк.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

17. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты тарафыннан бәяләү критерийлары нигезендә биш баллы система буенча бәяләнә. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

18. Иң күп балл җыйган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре дип танылa.

19. Призлы урыннар түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:

- 1 нче урын - «Татар малае - 2021»;
- 2 нче урын;
- 3 нче урын;
- «Иң талантлы малай»;
- «Иң матур сәхнә образы өчен»;
- «Иң милли җанлы малай»;
- «Иң камил малай»;
- «Милли традицияләрдә тәрбияләнгән малай»;
- «Иң оста телле малай»;
- «Иң акыллы малай».

20. Конкурсның җиңүчеләре дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева